РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

بسم الله الرحمن الرحيم

# Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдиннең Гыйд әл-Фитр (Ураза бәйрәме) белән КОТЛАВЫ

**Мәскәү**
1 шәүвәл 1437 ел
5 июль 2016 ел

# БИСМИЛЛӘҺИР-
# РАХМӘНИР-РАХИМ

*Рәхимле вә Рәхмәтле Аллаһу Тәгалә*
*исеме белән сүз башлыйм!*

Кадерле ир һәм кыз туганнарым, хөрмәтле газиз дин кардәшләрем!
Аллаһу Сөбханә вә Тәгаләнең рәхмәте, бәрәкәте һәм мәрхәмәте, ике дөния сәламе дә барчаларыгызга булса иде!

Бу җәйге көннәрдә безләргә изге Рамазан уразасын күркәм төстә башкарып чыгарга ярдәм иткән, безләргә Үзенең чиксез рәхмәтләрен салып, исәпсез-хисапсыз әҗер-саваплары белән бүләкләгән Аллаһу Сөбханә вә Тәгаләгә бөтен олуглауларыбыз, мактауларыбыз булса иде!

Аллаһу Раббыбыз Коръәни Кәримендә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

***«Ий, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгәне кеби, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!»***
*(2:183)*

Бүгенге изге бәйрәмебездә, мөбарәк Гыйд әл-Фитр (Ураза бәйрәмендә) барлык дин кардәшләремне, илебезнең төрле калаларында һәм авылларында яшәүчеләрне Ураза гаете белән котлап, Рамазанның төннәрендә һәм көннәрендә Аллаһу Тәгалә ризалыгы өчен дип ихластан тоткан уразаларыбызны, кылган догаларыбызны, биргән сәдакаларыбызны һәм эшләгән изгелекләребезне кабуллардан ит дип дога кылып калам. Каләме Шәрифтә әйтелә:

قَدْ أَفْلَحَ مَنْ تَزَكَّى وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلَّى

***«Мөшриклектән вә монафикълыктан, рия вә бидәгать гамәлләрдән, фәхеш вә хәрам эшләрдән үзен пакьләгән һәм саклаган кеше, тәхкыйк, газаптан котылып өстенлек тапты. Вә ул кеше, Раббысын зикер итеп намаз укыды».***
*(87:14-15)*

Аллаһның бу сүзләре безнең барыбызга да – Рамазан уразасын тотып калебен пакьлаган, төннәрен гыйбадәттә үткәргән, зәкать әл-фитр сәдакасын биргән һәм Аллаһу Сөбханә вә Тәгаләне мактап, ошбу изге айны тәмамлаган бүгенге бәйрәм намазында катнашучыларга карата әйтелә дияргә мөмкин.

Галәмнәрне бар кылган Аллаһу Тәгалә әмерен – камиллеккә ирешү һәм иманнарыбызны ныгыту чарасы булган әлеге гыйбадәтне үтәп, бүген без инсаннарга хас булганча, яңа көч белән рухи пакьлану һәм күтәренкелек хисләре кичерәбез. Бу пакьлануга шатланган хәлебездә, безләргә шушы Рамазан уразасы нигъмәтләрен биргән Аллаһу Сөбханә вә Тәгаләгә ихлас рәхмәтләребезне, мактауларыбызны җиткереп, Аның сүзләре белән бөтен галәм ишетерлек итеп бәйрәм тәкъбирен әйтәбез:

**«Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр! Лә иләһә иллә ллаһу вә Аллаһү әкбәр!**
**Аллаһу әкбәр, вә ли-Лләһил хәмд!»**

**«Аллаһ бөек, Аллаһ бөек! Аллаһтан башка Иләһ юк, Аллаһ бөек!**
**Һәм барча мактаулар Аллаһу Сөбханә вә Тәгаләгә!»**

Рамазан ае тәмамлану белән, әлеге мөбарәк бәйрәмебезне билгеләп үткән якты көннәрдә алдыбызда тагын да җаваплырак бурыч торуын истән чыгармасак иде. Ул – әлеге гыйбадәтнең Аллаһу Тәгалә тарафыннан безләргә рухыбызны ныгыту, калебләребезне сафландыру өчен җибәрелгән. Изге айда ирешкән рухи пакьлыкны саклау һәм төрле гөнаһлардан һәм әхлаксызлыклардан тыелу – бу безнең бурыч.

Узган гасырның танылган дин галиме, күренекле ватандашыбыз Муса Җарулла Бигиев билгеләп үткәнчә: “Кеше үз ихтыяры белән тәмле ризыклар ашамыйча да ачыкмыйча, 2-3 көн буена эчмичә дә сусамыйча тора ала. Әмма бу хәл 30 көн буена сузылса, инсан нәфесен тыяргa гадәтләнә, теләк-рәхәтлекләрен ихтыяр көченә буйсындырырга күнегә. Мондый хәлләрдә һәркем үз теләкләренең хуҗасына әйләнә. Ачлыкны тоеп та, күңеле белән ризыктан тыелып торган, сусап та, эчәргә үрелмәгән инсан, әлбәттә, бервакытта да хыянәт, хәйлә-алдаулар кебек тыелган эшләргә бармас. Һәм мондый кеше нәфес теләкләренә бирелеп, бервакытта да пакьлек һәм хакыйкый чикләрне узмый, хак юлдан тайпылмый, һәрчак шәригать рөхсәт иткән чикләрдә кала. Икенче төрле әйткәндә, иләһи диннәр кануннарының максаты булып торучы бәхет-сәгадәткә ураза аша ирешелә”.

Дөреслектә, ай буена нәфесебезгә хуҗа булып, тоелып, үзебездә нәфесне идарә итәрлек көч барын расладык, рухи инануларыбызның җисми тойгылардан өстенлеген исбатладык. Без үзебезгә теләкләреңне канәгатьләндерү өчен генә яшәү ярамавын искәрттек, чын рухи канәгатьләнүнең матди кыйммәтләрдән булмыйча, ә рухи камилләшүдә икәненә төшендек. Чын шатлыкны төрле күңел ачуларда, юанычларда түгел, ә кешеләргә игелек кылуда һәм мохтаҗларга ярдәм күрсәтүдә булуына инандык.

Шушы Рамазан ае буена мөселманнарыбыз өйләренең, мәчетләрнең, махсус куелган “Рамазан шатерлары”ның ишекләрен киң ачып, барлык мохтаҗларны, туган-тумачаларын, дусларын һәм күршеләрен динен

һәм милләтен аермыйча, үзләре белән бергәләп авыз ачу шатлыгын уртаклашырга чакырдык.

Бу бәйрәм көннәрендә Рамазанда бирелергә тиешле (зәкать әл-фитр) фитра сәдакаларыннан меңләгән ятимнәргә һәм мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтелде, бүләк-күчтәнәчләр өләшенде. Әйдәгез, әлеге изге айда үзебездә булдырган бу матур гадәтне саклап, һәрчак юмарт, кеше хәленә керүчән, миһербанлы булырга тырышып, шушы изге гамәлләребез белән киләчәктә дә Аллаһу Сөбханә вә Тәгалә рәхмәтенә ирешергә омтылыйк!

Сүземнең азагында шуны искәртәсем килә: бик тиздән, тагын ике айдан Аллаһ кушса чираттагы бәйрәмне – Раббыбызның сөеклесе Ибраһим аләйһиссәләмне искә алуга багышланган Гыйд әл-Әдха (Корбан бәйрәмен) каршылыйбыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа ﷺ әйткәнчә: «Бу бөек исеменә Ул даими төстә игелек, яхшылыклар эшләве аша ирешә». Һәм бу сыйфатларны без изге Рамазан ае буена үзебездә тәрбияләргә тырыштык.

Аллаһу Сөбханә вә Тәгаләнең җир йөзенә җибәрелгән соңгы Пәйгамбәре Мөхәммәд ﷺ әйткән:

مَا اتَّخَذَ اللَّهُ إِبْرَاهِيمَ خَلِيلًا إِلَّا لِإِطْعَامِهِ الطَّعَامَ ، وَإِفْشَائِهِ السَّلَامَ ، وَصَلَاتِهِ بِاللَّيْلِ وَالنَّاسُ نِيَامٌ

***«Тирә-ягындагыларын ризык белән сыйлаган, тынычлык тараткан һәм кешеләр йоклаганда төннәрен гыйбадәттә үткәргән өчен Раббыбыз Ибраһимны Үзенең дусты итеп билгеләде».***

Аллаһу Тәгалә барчаларыбызга да хәерле сәламәтлекләр биреп, киләсе бәйрәмне дә күңел тынычлыгында һәм Үзенә карата мәхәббәт вә тәкъвалык саклап каршыларга насыйп булсын дип дога кылам. Аллаһу Сөбханә вә Тәгалә иманнарыбызны ныгытып, Үзенең юлында изгелекләребезне арттырып, якыннарыбызга карата күңелләребезгә миһербан-шәфкать орлыклары салып, Ватаныбызны һәм барлык кешелекне рәхмәтеннән ташламасын, ил-көннәребез тынычлыгын, мул тормышлар насыйп итсен!

Әс-сәләму аләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ!

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин***

*Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе*

*Россия Мөфтиләр Шурасы рәисе*